**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 11 июнендәге 2440 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Киров районы Тимерьюлчылар урамы буенча ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган гавами сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 62 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры 16:50:280840:13 һәм хокуклар чикләнә торган кварталның кадастр номеры 16:50:280840;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Киров районы, Тимерьюлчылар урамы;

- билгеләү вакыты: электр челтәре хуҗалыгы объекты – җирле әһәмияттәге ТП-1764 трансформатор подстанциясен урнаштыру;

- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләүгә нигезләр: гариза бирүченең мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы (2018 елның 21 декабрендәге редакциядә) «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында»гы карары, Казан шәһәр Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, җирле әһәмияттәге ТП-1764 трансформатор подстанциясенә милек хокукы теркәлгән (2001 елның 26 декабре, №16-50.3-23.2001-1288.3)

2. Әлеге карарның 1 һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән һәм кадастр кварталы өлеше территориясеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнары рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2024 елның
11 июнендәге 2440 номерлы
карары белән расланган
1 номерлы кушымта

**Җир кишәрлегенең бер өлешенә һәм кадастр кварталы территориясенең бер өлешенә ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштабы 1:500
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| — (яшел сызык) | билгеләнә торган сервитут чиге |

| | |
|---|---|
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдаланунын махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:280840 | кадастр кварталы |
| 16:50:280840:13 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

______________________________